ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

«25» апрель 2023 ел — № 466

**2023 елга муниципаль юл фонды акчалары хисабына Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында юл эшләре муниципаль программасын раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә Арча муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2023 елга муниципаль юл фонды акчалары хисабына Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында юл эшләре программасын кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районы башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы И.Ә. Кадыйровка йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы — И.Ә. Галимуллин

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ИНН 1609009516

Арча муниципаль районы
Башкарма комитетының
25.04. 2023 ел, №466
карары белән расланды

# 2022 ЕЛГА МУНИЦИПАЛЬ ЮЛ ФОНДЫ АКЧАЛАРЫ ХИСАБЫНА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ҖИРЛЕ ӘҺӘМИЯТТӘГЕ ГОМУМИ ФАЙДАЛАНУДАГЫ АВТОМОБИЛЬ ЮЛЛАРЫНДА ЮЛ ЭШЛӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАСЫ

# ПРОГРАММАНЫҢ ПАСПОРТЫ

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | 2023 елга муниципаль юл фонды акчалары хисабына Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында юл эшләре муниципаль программасы |
| Программаны эшләү өчен нигез | 1.Россия Федерациясе бюджет кодексы<br>2. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон<br>3.Татарстан Республикасы бюджет кодексы<br>4.«2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2022 елның 23 ноябрендәге 78-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы.<br>5. 2023 елга Татарстан Республикасы юл эшләре программасы («2023 елга Татарстан Республикасының гомуми файдаланудагы юлларында юл эшләре турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 елның 25 гыйнварындгаы 42 номерлы карарына кушымта).<br>6. 2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Арча муниципаль районы бюджеты.<br>7. «Муниципаль юл фондын төзү һәм муниципаль юл фондының бюджет ассигнованиеләрен формалаштыру һәм куллану тәртибен раслау турында» Арча район Советының 2013 елның 12 октябрендәге 232 номерлы карары.<br>8. 2023 елга җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы юлларда муниципаль юл эшләре программаларын гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән муниципаль юл фонды ассигнованиеләре күләме |
| Программаның координаторлары | 1. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы<br>2. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы<br>3. «Татарстан Республикасы юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерүнең төп идарәсе» ДКУ<br>4. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаның заказчысы | Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты |

| | |
|---|---|
| Программаны төп эшләүче | Арча муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге |
| Программаның максатлары һәм бурычлары | 1. Арча муниципаль районы торак пунктларындагы күпфатирлы йортларның ишегалды территорияләрен, күпфатирлы йортларның ишегалды территорияләренә керү юлларын ремонтлау һәм капиталь ремонтлау, җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары эшчәнлеген тәэмин итү<br>2. Арча муниципаль районы торак пунктларының юл-урам челтәре юлларын төзү, реконструкцияләү һәм ремонтлау юлы белән норматив хәлгә китерү<br>3. Җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында хәрәкәт иминлеген тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыру |
| Программаның максатчан күрсәткечләре | Муниципаль юл фонды акчаларын туплау һәм тоту |
| Гамәлгә ашыру сроклары | 2023 ел |
| Программаны финанслауның чыганаклары һәм күләмнәре | 2023 елга муниципаль юл фонды ассигнованиеләре күләме 38 200 000 сум тәшкил итә<br>Муниципаль юл фондының 2023 елның 1 гыйнварына калган акчалары 7 421 137,86 тәшкил итә<br>(Җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында хәрәкәт иминлеген тәэмин итү чараларын башкару)<br>Финанслау чыганаклары<br>1. Россия Федерациясе территориясендә җитештерелә торган турыдан-туры куыла торган бензинга, автомобиль һәм дизель ягулыгына, дизель, карбюратор һәм инжектор двигательләре өчен мотор майларына акцизлар<br>2. Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр рәвешендә керемнәр (финанслау чыганагы варианты)<br>3. Физик һәм юридик затлардан, шул исәптән ирекле иганәчеләрдән керемнәр (финанслау чыганагы варианты)<br>2023 елга лимит - 38 200 000 сум<br>Ел башына калган акча - 7 421 137,86 сум |
| Программаны тормышка ашыруның | 1. Халыкның тормыш дәрәҗәсе күтәрелү<br>2. Юл хәрәкәте иминлеге үсү<br>3. Районның инвестиция җәлеп итүчәнлеге арту |

| | |
|---|---|
| көтелгән ахыргы нәтиҗәләре Финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | 4. Хуҗалык итүче субъектларның һәм муниципаль районның гомуми социаль-икътисади үсеше |

**1. Гомуми нигезләмәләр**

1.1. Муниципаль юл фонды Россия Федерациясе Бюджет кодексының 179.4 статьясындагы 5 пункты нигезендә формалаша һәм кулланыла.

1.2. Муниципаль юл фонды - җирле (муниципаль) әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында юл эшчәнлеген финанс ягыннан тәэмин итү максатларында (төзү һәм ремонтлау), шул исәптән юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү, күпфатирлы йортларның ишегалды территорияләрен, ишегалды территорияләренә керү юлларын ремонтлау һәм капиталь ремонтлау чараларын гамәлгә ашыру өчен муниципаль берәмлек бюджеты акчаларының бер өлеше.

1.3. Юл фонды акчалары максатчан билгеләнешкә ия һәм юл эшчәнлеген тәэмин итүгә бәйле булмаган ихтыяҗларга тотылырга тиеш түгел.

**2. Юл фонды барлыкка килү чыганаклары**

2.1. Юл фондының бюджет ассигнованиеләре күләме чираттагы финанс елына һәм план чорына җирле бюджет турында Арча муниципаль районы Советы карары белән җирле бюджетның фаразланыла торган түбәндәге керемнәре күләменнән ким булмаган күләмдә раслана:

1. Чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән расланган дифференциацияләнгән бүленеш нормативлары нигезендә Россия Федерациясе территориясендә җитештерелә торган турыдан-туры куыла торган бензинга, автомобиль һәм дизель ягулыгына, дизель, карбюратор һәм инжектор двигательләре өчен мотор майларына акцизлар. Муниципаль юл фондының бюджет ассигнованиеләре күләменә, хисап финанс елында фактта ирешкән һәм аны төзегәндә әлеге пунктта күрсәтелгән җирле бюджет керемнәре күләме арасындагы аерманы исәпкә алып, чираттагы финанс елында төзәтмәләр кертергә тиеш.

2.2. Юл фондының агымдагы финанс елында файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләре чираттагы финанс елында юл фондының бюджет ассигнованиеләрен арттыруга (юл хәрәкәте иминлеге чараларын тәэмин итүгә) юнәлдерелә.

## 3. Юл фонды акчаларын тоту юнәлешләре

3.1. Муниципаль юл фонды акчалары түбәндәгеләргә юнәлдерелә:

1. Җирле (муниципаль) әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын проектлау, төзү, реконструкцияләү, ремонтлау, капиталь ремонтлау һәм карап тоту;

2. Күпфатирлы йортларның ишегалды территорияләрен, торак пунктларда күпфатирлы йортларның ишегалды территорияләренә керү юлларын ремонтлау һәм капиталь ремонтлау.

3. Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча чаралар башкару.

3.2. 2023 елга юл фондының бюджет ассигнованиеләре күләмен объектларга бүлү әлеге программага кушымтада күрсәтелде. Әлеге кушымта Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең 2023 елда муниципаль юл фонды акчаларының бер өлешен юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү чараларына куллану турындагы карары нигезендә әзерләнде.

## 4. Юл фонды акчаларын тотуны тикшереп тору

Юл фонды акчаларын тотуны тикшереп торуны Арча муниципаль районы Башкарма комитеты, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының 9 нчы территориаль бүлеге, «Главтатдортранс» ДКУ башкара.

2023 елга муниципаль юл фонды
акчалары хисабына Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы җирле әһәмияттәге
гомуми файдаланудагы юлларда
юл эшләре муниципаль программасына кушымта

2023 елга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы юлларда юл эшләре программасына кертелгән җирле әһәмияттәге объектлар исемлеге

| № | Объектның исеме | Км, м, кв. м | Гамәлдәге бәяләрдә капиталь кертемнәр, мең сум |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1 | Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Түбән Мәтәскә авылында 500 укучыга исәпләнгән мәгариф учреждениесенә автомобильләр өчен парковка ясалган керү юлы | 4680 кв. м | 22 577.226 |
| 2 | Арча шәһәре, Бакый Урманче урамында 48 фатирлы 18 йорт янында юллар, парковка, тротуарлар | 2856 кв.м | 13 676.144 |
| 3 | Сөрде авыл мәдәният йортын төзекләндерү | 100 кв. м | 548.570 |
| 4 | Чулпан авылында ФАП янында парковка | 70 кв. м | 395.868 |
| 5 | Яңа Кишет авылында җирле үзидарә Советына килү юлы һәм парковка | 200 кв. м | 1 002.188 |
| **2023 елга муниципаль юл фонды планы буенча барлыгы** | | | 38 200.000 |
| | | | |
| I. | 2023 елга бюджет йөкләмәләрен үтәү | - | - |
| II. | Тотылмаган акчалар, шул исәптән юл хәрәкәте иминлеге чаралары хисабына: | - | - |
| 1 | Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Түбән Мәтәскә авылында 500 укучыга исәпләнгән мәгариф учреждениесе янында тротуар салу | 470 м | 4 745.000 |
| 2 | Арча шәһәре, Вахитов урамында юл билгеләре белән ясалма тигезсезлекләр төзү | 1 данә | 75.000 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 3 | Арча шәһәре, М.Жуков урамы, 2 йорт, 5 йорт каршында юл билгеләре белән ясалма тигезсезлекләр төзү | 2 данә | 150.000 |
| 4 | Арча шәһәре, Молодёжная урамы, 32 йорт каршында юл билгеләре белән ясалма тигезсезлекләр төзү | 1 данә | 75.000 |
| 5 | Арча шәһәре, Мостовая урамы, 5 йорт каршында юл билгеләре белән ясалма тигезсезлекләр төзү | 1 данә | 75.000 |
| 6 | Арча шәһәре, 90 лет ТАССР урамы 33, 47, 49 йортлар каршында юл билгеләре белән ясалма тигезсезлекләр төзү | 3 данә | 225.000 |
| 7 | Арча шәһәре, Нагорная урамы, 30 йорт каршында юл билгеләре белән ясалма тигезсезлекләр төзү | 1 данә | 75.000 |
| 8 | Арча шәһәре, Комсомольская урамы, 74 йорт каршында, Арча шәһәре, Западная урамы, 80 Б йорт каршында юл билгеләре белән ясалма тигезсезлекләр төзү | 2 данә | 150.000 |
| 9 | Мәктәп транспорты йөрүне тәэмин итү өчен тукталыш пунктларын төзекләндерү. Павильон, утырту мәйданчыгы, туктау кесәсе, юл билгесе, аншлаг. 1. 1 Казанка авылы 2. Казанбаш авылы | 2 берәмлек | 1 851.13786 |
| **2023 елның 01 гыйнварына муниципаль юл фондының фактта калган акчалары буенча** | | | 7 421.13786 |